**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 19 октябрь № 758

г. Казань

Халыкның яшәү сыйфатын һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары мониторингы өчен мәгълүматлар составын һәм аларны бирүнең кабатлануын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары үз көчен югалтуны тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Халыкның яшәү сыйфатын һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары мониторингы өчен мәгълүматлар составын һәм аларны бирүнең кабатлануын расларга (теркәлгән).

2. Үз көчен югалтуны танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкның тормыш сыйфатын, Татарстан Республикасы министрлыклары, ведомстволары һәм тапшырылган дәүләт вәкаләтләре нигезендә җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары мониторингы өчен Татарстан Республикасы министрлыклары, ведомстволары тарафыннан мәгълүматлар кертү регламентын раслау турында» 2008 ел, 13 октябрь, 750 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкның тормыш сыйфатын, Татарстан Республикасы министрлыклары, ведомстволары һәм тапшырылган дәүләт вәкаләтләре нигезендә җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары мониторингы өчен Татарстан Республикасы министрлыклары, ведомстволары тарафыннан мәгълүматлар кертү регламентын

раслау турында»  2008 ел, 13 октябрь, 750 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 ел, 26 май, 379 нчы карары.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\758.docx